Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Иске Михайловка авыл Советы

КАРАР

8 апрель 2026 ел № 13

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл Советының 2022 елның 05 августындагы 56 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлеге сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка _ авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турында» карарның үз көчен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Иске Михайловка авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл Советының 2022 елның 05 августындагы 56 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлеге сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе турында» карарның үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Әлмәт районы, Иске Михайловка авылы, Школьная урамы, 43 йорт, Ирекле авылы, Лесная урамы, 1а йорт, территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Иске Михайловка авыл
җирлеге Башлыгы А.Ю.Зарубин